КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1189

Татарстан Республикасы Министр-
лар Кабинетының кайбер карарла-
рына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм аларның хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Хуҗалык идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты эшләре идарәсенең Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы һәм Татарстан Республикасы Президенты эшләре идарәсенең Кунак йорты эшчеләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең 1 нче – 12 нче разрядлары буенча тариф ставкаларына арттыру коэффициентларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 21 ноябрь, 547 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 декабрь, 643 нче; 2007 ел, 18 октябрь, 575 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең 6 нчы – 12 нче разрядлары буенча тариф ставкаларына арттыру коэффициентларын билгеләү

турында»;

әлеге карарга кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге эшчеләре өчен Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре разрядларының тариф ставкаларына карата арттыру коэффициентларын билгеләү турында» 2005 ел, 28 декабрь, 637 нче карары кушымтасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 август, 748 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта:

1 пунктчада «50» саннарын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

5 пунктчада:

икенче абзацта «25» саннарын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» саннарын «2» санына алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» саннарын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» саннарын «10» саннарына алмаштырырга;

7 пунктта «1 дән 12 гә кадәр» сүзләрен «6 дан 12 гә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктчада «6 айлык тариф ставкасы» сүзләрен «1 айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктчада «9 айлык тариф ставкасы» сүзләрен «1,8 айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «3 айлык тариф ставкасы» сүзләрен «1 айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне

исәпкә алып, 2 айлык тариф ставкасы» сүзләрен «1 айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта:

1 пунктчада «50» саннарын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

5 пунктчада:

икенче абзацта «25» саннарын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» саннарын «2» санына алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» саннарын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» саннарын «10» саннарына алмаштырырга;

8 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

5. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 21 ноябрь, 547 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең 6 нчы – 12 нче разрядлары буенча тариф ставкаларына арттыру коэффициентлары

| Разряд | Арттыру коэффициенты |
|---|---|
| 6 | 1,25* |
| 7 | 1,04 |
| 8 | 1,05 |
| 9 | 1,06 |
| 10 | 1,09 |
| 11 | 1,16 |
| 12 | 1,22 |

*«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең җиңел автомобильләр йөртүчеләре өчен.

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 28 декабрь, 637 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеге эшчеләре өчен Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре разрядларының тариф ставкаларына арттыру коэффициентлары

| Разряд | Арттыру коэффициенты |
|---|---|
| 2 | 1,06 |
| 3 | 1,13 |
| 4 | 1,15 |
| 5 | 1,17 |
| 6 | 1,23 |
| 7 | 1,33* |
| 8 | 1,44* |
| 9 | 1,57 |

*Җиңел автомобильләр йөртүчеләр өчен арттыру коэффициенты кулланыла:
7 нче разряд буенча – 1,48;
8 нче разряд буенча – 1,61.